# Нәсыйхәт

җомга
25
февраль 2011
№ 1

**Рәхимле вә Шәфкатьле АЛЛАҺ исеме белән**
**Мамадыш мәдрәсәсенең айлык дини-иҗтимагый газетасы**




# Баш мөхәррир сүзе

Хөрмәтле мөселманнар! Беркемгә дә сер түгел: динебезнең нигезе – белем. Коръәни Кәримнең иң беренче рәсүлебезгә иңгән аяте дә "Укы" дигән сүз белән башлана. Раббыбыз Адәмне (Аллаһының аңа сәламе булсын) башка мәхлүкаттан белем белән аерды. Аллаһы Тәгалә шушы белеме нигезендә Адәмне һәм аның булачак буынын Җир шарына хуҗа итеп билгеләде. Шуңа күрә шәригатебез дә бөтен нәрсәне белем нигезендә эшләргә куша. Бүген, Аллага шөкер, дин өйрәнергә, гыйлем алырга күп мөмкинлекләр бар. Мәчетләребез салына, мәдрәсәләребез эшли, китаплар басыла, газета-журналларда мәкаләләр чыгарыла. Боларны безнең ата-бабаларыбыз күрмәгән. Шуның өчен, бу яңарышлар динебезне күтәрү юнәлешендә безгә зур мөмкинлекләр тудыра. Шушы максатны күздә тотып, Аллаһының рәхмәте илә, без дә сезнең игътибарыгызга "Нәсыйхәт" газетасының беренче санын тәкъдим итәбез. Бу газета Мамадыш мәдрәсәсе мөгаллимнәре һәм шәкертләре ярдәмендә хезмәт кылынды. Аның сәхифәләреннән сирпелгән гыйлем нуры сезнең дә күңелләрегезне яктыртыр дип өметләнәбез.

Аллаһы Тәгалә илләребезгә иминлек, җаннарыбызга иман, тәннәребезгә исәнлек, саулык бирсен. Хәерле хә-ләл кәсепләр белән тапкан малларыбызның игелеген күреп, гаилә бәхете белән Аллаһының мәңгелек рәхмәтенә ирешергә насыйп булсын! Газетабызның сәхифәләре тирән эчтәлекле, гомере озын булсын!

**ГАБДРАХМАН хәзрәт ХӘБИБУЛЛИН,**
**Мамадыш мәдрәсәсе директоры.**

# Мәдрәсәнең кадерен белик

*Белем алу-бөтен кешегә дә фарыз гамәл. Юкка гына пәйгамбәребез (с.г.в) үзенең бер мөбарәк хәдисендә: "Туганнан алып, ләхеткә кадәр белем алыгыз," - дип әйтеп калдырмаган. Әгәр дә чал тарихыбызга күз салсак сәхәбәләр, галимнәребезнең ничек белем алганнарын беләбез. Бер хәдисне белер, өйрәнер өчен әллә ничә көннәр юлда үткәргән һәм аларны туплап, безгә кадәр түкми-чәчми җиткергәннәр, барысы да пәйгамбәребез (с.г.в) әйтеп калдырганнарга нигезләнеп, Аллаһы юлына үзләренең тормышларын багышлаганнар алар. Пәйгамбәребезнең (с.г.в) "Белем алу бөтен мөселманга фарыз" дигән хәдисен ишеткәч, мин уйланып калдым һәм мәдрәсәгә килдем. Мин укыган газеталарда мәдрәсәләр турында язучылар бик сирәк. Шуңа күрә биредәге тормышыбыз хакында тулырак сөйләргә булдым.*

**(Башы. Ахыры 3нче биттә).**



## Фәлсәфә

*Бер галимнең берничә шәкерте була. Аларның берсе гыйлем алуга аеруча хирыс икән. Ул остазын сынап карарга уйлый: болынга чыгып күбәләк алып керә дә: "Әй, укытучым, минем кулымдагы күбәләк тереме, үлеме?" - дип сорый. Үзе: "Тере дисә-үтерәм, үле дисә–очыртып җибәрәм, "-дип уйлый. " Әй, укучым, барысы да синең кулыңда",–дип җавап кайтара остаз. Күбәләкнең тере яисә үле булуы – аның үз кулында икәнлегенә ишарә итә. Чыннан да, бәхет күбәләге кешенең үз кулында.*

# ИСЛАМДА ТЕРРОРИЗМГА УРЫН ЮК!

Бүгенге көндә барыбыз да, төрле газеталардан укып, телевизордан ишетеп, күреп, дөньяда булган төрле шартлаулар, кеше үтерүләр турында, гомумән алганда, террорчылык хакында беләбез. Нәрсә соң ул террорчылык? Ислам динебез кеше үтерүгә ничек карый? Кемнәр алар үзләрен иманлы дип әйтеп, кешеләрне шартлатучылар? Бу сораулар барыбызны да борчый. Хөрмәтле дин кардәшләрем, газиз мөселманнар! Террорчылык–ул дәүләтнең һәм җәмгыятьнең җимерелүенә китерә торган иң зур җинаятьләрнең берсе, кешеләрне куркыту, газаплау булып тора. Бер генә дин дә, кешеләргә зыян китерүгә, кешене рәнҗетергә, кимсетергә, үтерергә өндәми. Барча диннәрдә дә бу гамәлләр зур гөнаһ булып санала. Аллаһы Раббыбыз: “Кешеләрне хисап кылучы – Мин» — ди. Беркемнең дә кемнедер кимсетергә, аны җәзаларга хакы юк. Кеше үтерү, газаплау, кимсету ул – Аллаһы Тәгаләгә, анын хөкемнәренә каршы бару. Беркемнең дә үз –үзен үтерергә хакы юк. Бу эшләрне башкарган бәндә имансыз була. Аңа–Аллаһының мәңгелек газабы. Аллаһы Тәгалә Корьән - Кәримнең «Әнгәм» сүрәсенең 151нче аятендә: «Аллаһ дөньяга яраткан бәндәләрне үтермәгез. Җәберләмәгез,» - ди. Шулай ук Аллаһы Тәгалә «Мәидә» сүрәсенең 32нче аятендә:«Кем дә кем бер кешене дөньяда үтерсә, бөтен кешеләрне үтергән кебек гөнаһлы була,”–ди. Ягьни, хөрмәтле мөселманнар, бу аятьләрдә Аллаһы Раббыбыз шушы әшәке эшләрне башкаручының Аллаһка каршы кеше икәнлеген безгә аңлата. Сөекле пәйгамбәребез гәләйһи вә сәлләм, бер хәдисендә болай диде: «Кыямәт көнне, дөньяда яшәгәндә кешеләрне рәнҗетүче, кешеләрне үтерүче һәм үз-үзенә кул салучы, җәннәткә кермәс, хәтта җәннәтнең исен дә исни алмас, шушы эшләре өчен мәңгелек газапка дучар булыр,»–диде. Бу хәдисләрдән без аңлый алабыз: «Бу гамәлләрне эшләгәндә кеше Аллаһының ачуына дучар була, үзен һәлакәт чокырына төшерә».

Хөрмәтле дин кардәшләрем! Бу яман эшләрне кемнәр башкара һәм алар кемнәргә файдалы соң? Элекке заманнарда казыйларыбыз да бер җинаять эше башкарылганда:”Бу кемнәргә файдалы соң?”–дип сорау бирәләр иде. Бүгенге көндә төрле массакүләм мәгълүмат чараларының, бу эшләрне мөселманнар башкара дип әйтүләре бик зур ялгышлык, чөнки, ул җинаятьчеләр мөселманнарга карата да җинаять кылалар. Әле күптән түгел генә Кабарда-Балкар мөфтие җинаятьчеләр тарафыннан атып үтерелде, имамнарга һөҗүм ителде. Шул сәбәпле бу яман эшләрне башкаручылар ниндидер дин вәкиле дип әйтү ярамый. Ислам дине, һәм бер генә дин дә җинаять кылырга өндәми. Ислам дине ул — тынычлык, иминлек, татулык дине, һәм шушы сыйфатларга ия булырга чакыра. Мәгълүм булганча, теләсә кайсы дин —массакүләм идеология булып тора. Диннәр аша үзләренең начар максатларына, ниятләренә ирешергә теләүчеләр һәрвакыт булган. Шул исәптән, ислам дине дә читтә калмаган. Исламның чыганакларын үзләренчә аңлатып, бу кешеләр динебезгә, мөселманнарга һәм гомумән кешеләргә зыян китерәләр. Ә бит Аллаһы Раббыбыз безләргә: «Имансызлар, динегезгә зыян китермәсәләр, йортларыгыздан куып чыгармасалар, аларга мәрхәмәтле булып, тату яшәгез»–дип әйтә. Корьәни -Кәримнең «Мүмтәхинә» сүрәсенең 8нче аятендә: «Аллаһы Раббыгыз дөрес, тату яшәгәннәрне сөя,»–ди. Хәтта пәйгамбәребез вә гәләйһи сәлләм, күршесендә яшәгән имансыз бер бәндәгә һәрвакыт мәрхәмәтле булган, аны дингә өндәгән, беркайчан да аңа карата зыян китермәгән. Бүгенге көндә диндә булмаганнар да исламның үсешенә зур өлеш кертәләр, динбезнең көчәюенә дәүләтебез дә ярдәм кулын суза. Безгә, шушы мөмкинлекләрне файдаланып, рухи мирасыбызны, күркәм гадәтләребезне торгызып, халыкны иманга өндәргә, динне көчәйтергә тырышырга кирәк.

Газиз дин кардәшләрем! Бу фани дөньяга, әлхәмдүлилләһ, Аллаһы Тәгалә барыбызны да иман белән, мөселман итеп яратты, һәм безләрне Корьән-Кәрим белән нигьмәтләндерде. Шушы Аллаһының юлы белән барырга тырышыйк, аның хөкемнәрен дөрес аңлыйк, аңламасак, белгәннәрдән сорашыйк. Кеше рәнҗетүдән сакланыйк. Мөселманнарга да, барча халыкка да зыян китерүдән ерак булыйк. Бу яман эшләрне башкаручыларга да, Аллаһы Раббыбыз тәүфикь-хидәят биреп, аларны туры юлга бастырса иде. Безләргә, барчаларыбызга да, Раббыбыз иман байлыгы биреп, калган тормышыбызны да иманлы булып яшәп, дөньядан мәңгелеккә күчкәндә дә иман белән күчеп, шушы дөнья һәм ахыйрәт бәхетенә ирешергә насыйп әйләсә иде. ӘМИН.

**ЛЕНАР ХАММАТОВ интернет материаллары кулланып әзерләде.**

**P.S. Минем күп кенә дусларым (исламда булмаганнары) без – мөселманнар турында төрле кинолар карап, газеталардан ялган мәкаләләр укып, дөрес булмаган уй-фикерләргә киләләр. Хәтта үзләренә дә сәер тоелган сораулар бирәләр. Шул сорауларына җавап эзләп менә нинди фикергә килдем. Җәмгыятьтә тәртип һәм рухи үсешне тәэмин итүче чыганакларның иң мөһиме–әдәп-әхлак, ә күркәм әхлакның нигезе – дин, иман. Аллаһы Тәгалә кешеләргә туры юлны күрсәткән, хәләлне хәрамнан аерган һәм аларның чикләрен төгәл билгеләгән. Шул кануннар буенча яшәгәндә генә кеше бәхеткә, уңышка ирешә ала, дөньялыкта тормышы бәрәкәтле, ә ахирәттә киләчәге өметле була. Мәдрәсә шәкерте буларак шуны әйтәсем килә: Ислам бернинди дә начарлыкка өйрәтми, өндәми. Бары яхшылыклар, игелекләр кылу – безнең төп бурыч.**

**Хәдис: “Ислам дине биш терәккә нигезләнә: “ Аллаһыдан башка иләһ юк, Мөхәммәд аның илчесе”, - дип шаһәдәт бирү , намаз уку, зәкят түләү, хаҗ кылу, Рамазан аенда ураза тоту”.**

**Бохари, Мөслим риваятьләрендә килә.**

# Мәдрәсәнең кадерен белик



**(Ахыры. Башы 1нче биттә).**
Безнең мәдрәсә, әлхәмдүлилләһ, инде өченче ел матур гына эшләп килә. Районыбызда күп кеше әле мәдрәсә барлыгын белми дә бугай, бәлки нидәндер шикләнеп балаларын җибәрми торганнардыр? Тик сезнең шикләнүләрегез урынсыз.
Мәдрәсә шәһәрнең иң матур урыннарыннан берсе булган үзәк урамда урнашкан. Ул бик зур вә бик мәһабәт. Анда уку өчен бөтен уңайлыклар да бар. Мин биредә беренче мәртәбә аяк баскач таң калдым: аның гүзәллегенә, анда булган мохиткә, кергән кешеләрне шәкертләрнең шундый ягымлы итеп каршы алуына... “Нишләп мин монда алданрак килмәдем икән”,–дип уйлап куйдым.

Мәдрәсәдәге җәмәгать бер гаилә булып яши. Бер-беребезгә гел булышабыз, киңәшләр бирәбез. Берәр карар кабул иткәнче җыелышып киңәшләшәбез. Үз әчләренә генә бикләнеп яталар икән дип уйлый күрмәгез. Киресенчә, монда бик актив тормыш рәвеше алып барыла. Төрле ярышлар, бәйгеләр даими оештырыла. Пәйгамбәребез с.г.в. әйткән: “Көчле мөселман көчсезеннән хәерлерәктер, ләкин аларның икесендә дә хәер бардыр.” Кардәшләребез татарча көрәш, штанга күтәрү ярышларында гел мактаулы урыннарга лаек булалар. Беренчелекне кулдан төшергән юк әле. Үзебезнең арада да бик күп бәйгеләр оештырабыз. Җәй көннәрендә табигатькә чыгып ял итәбез. Шундый җыеннардан соң аралар тагын да якыная, укырга теләк тагын да көчәя.

Белем алырга теләүчеләр өчен мәдрәсәдә кичке, якшәмбе укулары оештырыла. Мәдрәсә ел саен 16-17 яшьлек малайларны укырга җыя. Әгәр дә сезнең балагыз бик яшь икән, бер дә борчылмагыз. Җәй көннәрендә малайлар һәм кызлар өчен лагерьлар оештырыла. Аларны анда ислам диненең нигезенә өйрәтәләр, күп җирләргә экскурсияләргә йөртәләр: төрле шәһәрләр, ислам дине белән бәйле булган тарихи җирләр һәркемдә кызыксыну уята. Балагыз лагерьдан һичшиксез яхшы якка үзгәреп кайтыр, иншаллаһ!

Хөрмәтле ата-аналар! Әгәр дә баланызның тәүфыйклы, мәрхәмәтле булып үсүен телисез икән, икеләнмичә мәдрәсәгә укырга бирегез. Пәйгамбәребез әйткән: ”Дөреслектә, юктыр шик шунда: фәрештәләр үзләренең канатларын белем артыннан баручы кешеләр өстеннән каплыйлар”.

**РАФИС ЗАКИРОВ,**
мәдрәсәнең 2нче курс шәкерте.

**Рәсемнәрдә:** уку–инә белән кое казу; бергә-бергә Нократ киңлекләрендә йөзү ничек рәхәт!.




## Сорау илә җавап

**– Белгәнебезчә, ялган–гөнаһ. Әгәр үз ихтыяҗларыңны кайгыртып түгел, ә кешене рәнҗетәсе килмәүдән алдаласаң ярыймы?**

– Ялган хәрам. Өч төрле очрактан кала: ике дусны дуслаштыру өчен, гаиләне саклап калу өчен һәм сугышта.

**– Мөселман балаларының гөнаһлары унбиш яшькә кадәр аларның ата- анасына күчә диган сүз дөресме ?**
– Дөрес түгел.

**–Тәнгә сурәт ясарга (татуировка) ярыймы?**
– Бу гамәл хәрам гамәлләрдән санала. Моның белән эш алып баручыларны пәйгамбәребез ләгънәт кылынганнар рәтенә кертә.

**– Ә дингә килгәнче ясалган булса?**
–Дингә кадәр булган һәрбер гөнаһ, хәдистән белгәнебезчә, дингә килгәч кичерелә.

**– Намаз эчендә сүрәләрне үз телеңдә (татарча) укырга ярыймы?**
–Намаз эчендә юк.

**–Киемдә сурәт булса, аның белән намаз укысаң ярыймы?**
–Бу очракта бу мәкрух булып тора, чөнки беләбез, сурәт булган җиргә фәрештәләр керми.

**– Нинди ике гөнаһ кешенең кылган бар савабын юкка чыгара?**
– Ширек, ата-ананы рәнҗетү, аларны тыңламау.

**–Укыганда әзрәк хата чыкса да Коръәнне укырга ярыймы?**
–Әйе, әгәр дә сез гел укуыгызны шомартып һәм үзегезнең дөрес укылышыгыз турында белгән кешеләрдән сорап торасы икән.

**–Әгәр киемдә бераз гына кан тамчысы булса, бу кием белән намаз укысам ярыймы?**
–Ярый, тик юсаң әйбәтрәк.

Шәкертләрнең сорауларына җавап бирде **ЛЕНАР ХАММАТОВ.**

# Имтиханга кергәндә укыла торган дога

*Дәрес хәзерләүне таһәрәт алып башлау әйбәттер. Нинди генә дәрес булса да, бисмилләһ белән башлау кирәк. Аннан соң, шушы дога укылыр:*




*Рабби зиднии гильмәү үә фәһмәү үә әльхикъниии би-ссаалихиин. Рабби шрах лии садьрии үә йәссир лиии әмрии үәхлүл гукъдәтәм мил лисәәнии йәфкаһүү каулии. Йәә хәәфизу, йәә ракыйбү, йә нәәсыйру, йәә Аллааһу. Рабби йәссир, үә ләә түгәссир, рабби тәммим бильхайр.*

*Раббым минем гыйлемемне һәм фәһememне арттыр, шулай ук мине изге бәндәләр белән кавыштыр. Раббым, минем күңелемне ачык әйлә, эшләремне миңа җиңел әйлә, минем телемдә булган төенне чиш, минем сүземне аңларлар. Йә саклаучы, йә күзәтүче, йә ярдәмче, йә Аллаһы. Раббым, җиңеләйт, авырайтма һәм ахырын хәерле әйләп тәмамла.*

*Имтиханга кергәндә, бигрәк тә өч, биш яки җиде мәртәбә Аятел көрси укылыр.*

## Татарлык

Уян әле, татар,
айдә, уян!
Мин әйтмимен
тирән йокыдан.
Тик төш күрдем:
Татарстан
Рәсәй картасында
юк сыман
Татар халкы күлә белеп яши,
Тетрәндереп яши
җиһанны,
Ләкин арабызда бар
шундыйлар:
Аермыйлар актан караны.
Концерт бара, шунда
бер юморист,
Мәзәк сөйләп кеше көлдерә,
Тамашачы суырып
барбарис
Попкорн ашап,
нидәндер көлә.
Көлә халык, көлә эчен тотып,
Әй, мәзәкче сөйли,
көлдерә.
Ләкин белми
безнең тамашачы:
Татар үзеннән үзе көлә.

Ата-ана хәзер бер кем түгел
Безнең яшьләр бүген
эш куша,
Ата-ана түгел, киресенчә
Тәрбияли бала, орыша.

Тик чын татар мондый
түбән түгел
Биек кыяда ул, зур үрдә,
Ләкин кыяның да үз
серләре,
Кирәк икән менә белергә.

## Китап алдым

Китап алдым кулга,
сабый кебек,
Тырышамын
укып китәргә.
Тик нигәдер
таныш хәрефләр дә
Буталалар
минем күзләрдә.
Сукыр мин,
яхшылыкны күрмим,
Чукрак та мин,
телсез күке дә.
Ак буяулар җитмәс
бетерергә
Кара тапны минем
күңелдә.
Йортсыз калу
әле берни түгел,
Ни булыр әгәр
китсә дуслар?
Хәтта кошларның да,
сайрыйм дисә,
Кочагына алучы
таллары бар.

**ЛЕНАР ХАММАТОВ**,
2нче курс шәкерте.

# Викторина

**Кадерле укучыларыбыз, сезгә Ислам тематикасына кагылган викторина сорауларын тәкъдим итәбез.**




1) Шамаилне укыгыз.
2) Аллаһы Тәгаләнең ничә исеме бар?
3) Мөхәммәд Пәйгамбәребез ничәнче елда туган?
4) Әнисе үлгәндә пәйгамбәребезгә ничә яшь иде?
5) Коръәннең 5 исемен атагыз.
6) Көннәрнең солтанын атагыз.
7) А. С. Пушкинның Коръән белән бәйле нинди шигыре бар?
8) Ислам тарихына кереп калган дүрт хәлифәнең исемен языгыз.
9) Нух пәйгамбәр ничә ел яшәгән?
10) Кәрьәни- Кәримдә ничә сүрә бар?
11) Дин өлкәсендә эшләгән 3 татар галимен языгыз.
12) Коръән кайсы айда иңә башлаган?
13) Мөхәммәдкә пәйгамбәрлек иңгәндә ничә яшь була?
14) Коръәннең иң озын сүрәсен атагыз.
15) Пәйгамбәребезгә (с.г.в.) вәхи кайсы фәрештә аркылы иңгән?
16) "Коръән" сүзенең гарәбчәдән тәрҗемәсе?
17) Беренче пәйгамбәрнең исемен атагыз.
18) Мөхәммәд пәйгамбәрнең сөт анасының исеме?
19) Ислам динен беренче кабул иткән ир-атның исеме?.
20) Намазны кая таба юнәлеп укыйбыз?
21) Ислам календаре кайсы тарихи вакыйгадан башлана?

**Җавапларыгызны 10нчы мартка кадәр җибәрүегез сорала.**
**Җиңүчене истәлекле бүләк көтә.**

## Монафыйк кем ул?

**Монафыйкның өч билгесе бар: сөйләсә – ялганлый, вәгъдә бирсә, боза, амәнәт тапшырылса, хыянәт итә».**

Ялган сөйләргә кешеләр күбрәк яшь вакытларында өйрәнәләр. Соңрак бу нәрсә гадәткә керә дә, кеше шуннан ләззәт таба башлый. Бервакыт Рәсүлебездән: «Мөэмин кеше куркак булырмы?» - дип сораганнар. Рәсүлуллаһ: «Булыр», - дигән. «Мөэмин кеше саран булырмы?» - дип сораганнар. Рәсүлуллаһ: «Булыр», - дигән. «Мөэмин кеше ялган сөйләрме?» - дип сораганнар. Рәсүлуллаһ: «Юк», - дип җавап биргән. Бу хәдистәге "вәгъдә"дән максат яхшы эш белән вәгъдә кылудыр. Әмма бозык һәм шәригатьтә тыелган эш белән вәгъдә кылып та, шул вәгъдәдә тормау монафыйклык галәмәте түгел, бәлки чын мөселманлык галәмәте була. Ислам хөкеменә күрә, яман ниятләр һәм бозык вәгъдәләр үтәлмәскә тиеш.

# Мамадыш мәдрәсәсенә рәхим итегез!

Мәктәпләрдә һәм дини укыту – тәрбия йортларында эшләү, Аллаһы Тәгаләнең чын динен хаклау һәм үстерү максатыннан чыгып Татарстан Җөмһүрияте Мөселманнары диния Нәзарәте каршындагы Мамадыш мәдрәсәсе алдагы уку елына шәкертләр туплый.

Белгечләр әзерләү көндезге уку рәвешендә алып барыла. Мәдрәсәгә тулы булган яки тулы булмаган урта белемле, яше 14-15 яшьтән дә ким булмаган егетләр кабул ителә. Шәкертләр мәдрәсә тулай торагында яшәү урыны һәм көненә 3 тапкыр ашау-эчү белән тәэмин ителәләр. Мәдрәсәдә белем алучылар шәкерт статусына ия булалар. Укыту планын һәм программасының барлык таләпләрен үтәгән, чыгарылыш имтиханнарын уңышлы тапшырган шәкертләргә квалификация комиссиясе карары нигезендә тиешле белгечлек алу турында шаһәдәтнамә бирелә. Укырга керү өчен кабул итү комиссиясенә түбәндәге документларны тапшырырга кирәк:

•Белем турында таныклык.
•086 – формасында сәламәтлек турында белешмә.
•Характеристика.
•Паспорт күчермәсе.
• 3х4 үлчәмендә 4 фотосүрәт.

Намаз укырга өйрәнергә һәм дини белемне үзләштерергә теләүчеләр өчен мәдрәсәдә кичке уку бүлеге һәм читтән торып уку бүлеге эшли.

"БИШЕКТӘН АЛЫП ЛӘХЕТКӘ КАДӘР ГЫЙЛЕМ АЛЫГЫЗ".

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең Бөек исемнәре булганга күрә, аны саклап тотуыгыз сорала**

**Баш мөхәррир: Хәбибуллин А.М. Мөхәррир урынбасары: Талипов Р.Р. Хәбәрче: Хамматов Л.Н.**
**Дизайн һәм верстка: Мингалиева Ф.Н., Нуриев И.М. Корректор: Спиридонова А.С.**
**Безнең адрес: Мамадыш шәһәре, Муса Җәлил урамы,8/28. mamadysh-medrese@mail.ru. Газета "Татмедиа" ААҖнең Мамадыш муниципаль районы"Нократ" мәгълүмат-матбугат филиалында басылды. Тираж татар телендә 250 данә.**